| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2019 Казан шәһәре № 3-25/э

Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 №3-13/э карары белән билгеләнгән озак сроклы хосусый тарифларга 2020 елга төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Кирәкле тулай керемне озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган электр энергиясен тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә тарифлар исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, 2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларның кирәкле тулай керемнәренә үзгәрешләр кертү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә хосусый тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 №3-13/э карарына (Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №3-14/э, 12.12.2019 №3-17/э карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1 | «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2018 | 180 893,24 | 99,66 | 0,56472 | 164 204,75 | 109,93 | 0,54610 |
| | | 2019 | 193 086,45 | 121,33 | 0,62050 | 193 590,15 | 130,04 | 0,63052 |
| | | 2020 | 183 471,41 | 200,97 | 0,87460 | 183 471,41 | 200,97 | 0,87460» |

3 нче кушымтаның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1 | «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 2018 | 258 011,64 |
| | | 2019 | 267 154,40 |
| | | 2020 | 261 688,95» |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев